# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Вильмон поселогында 2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

03 декабрь, 2024 ел №3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Оштырма-Юмья авыл җирлегенең Вильмон поселогында гражданнар җыены карар чыгарды:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Кукмара районы Оштырма-Юмья авыл җирлегенең Вильмон поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, үзара салым суммасының 100 % ы күләмендә ташлама билгеләнгән 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге баласын тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә катнашучы контракт хезмәте хәрби хезмәткәрләре һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

2) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Вильмон поселогында янгын сүндерү рукавларын, стволларны, кучермәләрне, колонкаларны, мотопомпаны карап тоту, сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка эш төрләре);

3) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Вильмон поселогының урам юл челтәрен карап тоту, кышын юлларны кардан чистарту һәм җәен территорияне чабу,

төзекләндерү; трактор һәм чапкыч өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, юл челтәрен карап тоту буенча башка эш төрләре) (Вильмон поселогы урамнарында юлларга вак таш җәю, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу, җәю, суүткәргеч торбалар урнаштыру, шартнамә буенча эш өчен түләү; юлларны карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

3. Әлеге карарны Оштырма-Юмья авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына http://pravo.tatarstan һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында kukmor.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Оштырма-Юмья авыл җирлеге
башлыгы: С.В. Тимофеев